


**Татарстан республикасы**
**Яр Чаллы шәһәре**
**Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 45нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**Шамил Усманов урамы, 34**
**Рәхим итегез**
**e-mail sch45_chelny@mail.ru**

**Туган телдә сөйләшеп**
**Яшим мин туган илдә,**
**Туган ил дигән сүзне дә**
**Әйтәм татар телендә.**

**Безнең 45 нче мәктәптә, укучыларда татар теле һәм әдәбиятына мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү эшенең күпбаскычлы системасы булдырылды. Бу эш дәресләрдә һәм дәресләрдән тыш чараларда системалы рәвештә алып барыла.**

2017-18 нче уку елында, татар теленнән уздырылган шәһәркүләм олимпиадаларда катнашып, яхшы нәтиҗәләргә ирештек.

Татар төркемнәре арасында татар теленнән Гарипов Булат (4в)-призер, Газизова Камилла (6в)-**12 нче** урын.

Рус телле укучылар арасында Кузнецова Ирина (6б)-**2 нче урын**, Сергеева Анастасия (5а)-**5 нче** урын, Алексеева Карина (7б)-**7нче урын**, Колчерин Николай(11а)- **6нчы урын** алдылар.

# Төрле бәйгеләрдә, чараларда актив катнашабыз. Нәтиҗәләребез - куанырлык.


















# Казан федераль университеты оештырган “Ана теле” онлайн – мәктәбендә күп кенә укучыларыбыз укып чыктылар һәм сертификатлар алдылар.



Сертификат об окончании

Настоящий документ подтверждает, что

**Diana Bakhtieva**

успешно завершил(а) курс

Основы Татарского Языка – Уровень 9 - Продвинутый

Дата присуждения

08.02.2018

EducationFirst



Сертификат об окончании

Настоящий документ подтверждает, что

**Gatina Ljasan**

успешно завершил(а) курс

Основы Татарского Языка – Уровень 8 - Продвинутый

Дата присуждения

13.02.2018

EducationFirst



Сертификат об окончании

Настоящий документ подтверждает, что

**Liliya Safargalina**

успешно завершил(а) курс

Основы Татарского Языка – Уровень 5 - Средний

Дата присуждения

06.02.2018

EducationFirst



Сертификат об окончании

Настоящий документ подтверждает, что

**Valeriy Kornilov**

успешно завершил(а) курс


Основы Татарского Языка – Уровень 5 - Средний

Дата присуждения

11.09.2017

EducationFirst

Туган тел көнен үткәрүгә алдан ук әзерлек башлана. Һәр сыйныф бер чара үткәрергә әзерләнә:стена газеталары бәйгесе, туган телдә иң матур шигырь сөйләүче, җырлаучы, биюче бәйгеләре үткәрелә.






Туган тел – һәркем өчен газиз. Ут телдә әби-бабаларыбыз сөйләшкән, әти-әниләребез сөйләшә. Туган тел көне быел да күңелләрне дулкынландырырлык, хәтердә калырлык булды.













21 Февраль
Халыкара туган
тел көне.
Туган
тел








КАК ВЫБРАТЬ
Туган
тел




Халыкара туган
тел көне.
тел




тел

# “Без бергә” акциясендә актив катнаштык





















МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!
КИЛӘЧӘКНЕ ҮЗГӘРТӘМ!
POW!
Massive
INDUSTRIALIZED POP
You AND mE

**Ел саен Республика күләмендә уздырыла торган “Мин татарча сөйләшәм”акциясендә катнашу безнең мәктәпнең матур традициясенә әверелде.**

**Безнең команда: «Аргамак», безнең девиз: «Аргамак беркайчан оттырмас, сездән куып тоттырмас!»**

**Максаты:укучыларда татар телендә сөйләшергә теләк тәрбияләү.**


УГОЛОК ЗДОРОВЬЯ
"НЕБОЛЕЙКА"
СӘЛАМӘТЛЕК ПОЧМАГЫ
ЛИТЕРАТУРНАЯ
СТРАНИЧКА
ӘДӘБИ СӘХИФӘ
ВЕСТИ ИЗ ЛЕСА
УРМАННАН ХӘБӘРЛӘР




Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.

Икесе дә безнең өчен,
Иң кирәкле, затлы тел.



Республикакүләм “Мин татарча сөйләшәм” акциясе кысаларында узган “Муса безнең йөрәкләрдә” бәйгесе үткәрдек. Укучыларыбыз

Муса Җәлил шигырьләрен сәнгатьле, матур итеп сөйләделәр.





# Музей экспонатлары аша укучыларда татар теленә мәхәббәт тәрбиялибез.







**Челтәрле сандык эчендә**
**Кыйммәтле хәзинәләр**
**Армый-талмый хезмәт иткән**
**Безнең уңган әбиләр.**

Балаларның иҗади эшчәнлегенә дә бик зур игътибар бирәбез. “Көмеш кыңгырау”, “Шәһри Чаллы” гәҗитләрендә, “Мәйдан”, “Ялкын” журналларында безнең укучыларыбызның шигырьләре, рәсемнәре һәм мәкаләләре даими рәвештә басылып тора. Сәләтле укучыларыбыз белән бу эшне бик уңышлы гына Гыйззәтуллина Кафия Мөбәрәкша кызы алып бара.



«Күңелләргә шигырь кирәк...»

Мин Яр Чаллы шәһәренең 45нче мәктәбендә тугызынчы елымны укыйм. Тугыз ел буе укыткан яраткан укытучым турында сезгә дә язасым килде. Безне татар теленнән Гыйззәтуллина Кафия Мөбәрәкша кызы укыта. Ул инде өлкән яшьтәге укытучы, ике оныгына әби булса да, безгә аның дәресләрендә бик рәхәт һәм күңелле.

Кафия апаны тырыш бал корты на тиңләр идем. Әдәбият дәресләрен гел яттан шигырь сөйләү белән башлап җибәрә ул. Һади абый Такташның

2



Данил ПЕТРОВ,
Чаллы, 45 нче мәктәп

Шагыйрьләр

Татарларда әдипләр күп:
Тукай, Җәлил, Исхакый.
Һәрбер язган әсәрләрдә
Алар үз халкын зурлый.


Халыкның язмышын алар
Алдан күрә белгәннәр.
Милләтне яшәртер өчен,
Утка-суга кергәннәр.

Үз милләтен яклап алар
Төрле эшләр кылганнар.
Татарның чын улы булып,
Тарихта эз алганнар.

Татарларда шагыйрьләр күп:
Тукай, Җәлил, Исхакый.
Аларның иseme һәрчак
Халык күңелендә балкый.

Альберт МИНЕЕВ,
Чаллы, 45 нче мәктәп

154



Горур Тукай

Язның ямьле бер көнендә
Һәйкәл янына килдек.
Тукай бабайны сәламлик,
Шигырен укыйк, дидек.

Һәйкәлне күргәч, сокланып,
Бик озак тордык карап.
Әкияттәге геройлар
Күчкән һәйкәлгә, гаҗәп.

Зур дөньяга Тукай карый,
Күтәреп горур башын.
Укыдык аның янында
«Шүрәле», «Кисекбаш»ын.

Тукай һәйкәлен куярга
Кемнең башына килгән?
Татар халкы горурлансын,
Күреп шагыйрен, дигән.

Бүген олылап шагыйрьне,
Халкым килә һәйкәлгә.
Остазына гөлләр куеп,
Рәхмәт сүзе әйтергә.

Розалия АРСЛАНОВА,
Чаллы, 45 нче мәктәп

Настя РЫБОЛОВЛЕВА,
Чаллы, 32 нче мәктәп

156

## Чаллы – яшьләр шәһәре

Яр Чаллы дип атаганнар,
Су буйлары тугайга
Яңа шәһәр төзегәннәр,
Урыны уңай булганга.

Чаллы дигән шәһәребез
Матур җирдә урнашкан.
Бу шәһәрне төзүдә
Күп милләтләр катнашкан.

Төзегән алар тырышып,
Шәһәр матур булсын, дип.
Киләчәк буын шушында
Үз тормышын корсын, дип.

КамАЗ заводлары бүген
Бөтен илгә танылган.
Чаллы бөтен Россиядә
Яшь шәһәр, дип дан алган.

Яр Чаллыда туып үскән
Никадәрле балалар!
Алар бүген «Дакар»ларда
Җиңү яулап алалар.

Илләр саен хәзер нинди
Ярышлар гына булмый.
Әмма КамАЗны узардай
Машиналар табылмый!

*Гүзәл Халилова,*
*9 «Б» сыйныфы укучысы.*

7

## Тугры солдат

Сугыш башлануга, Алиш,
Корал алып кулына,
Илне саклаучылар белән
Китә сугыш кырына.

Әсирлектә дә, юк, Алиш
Антына тап төшерми.
Дошманга бирешми, аңа
Горур башын ул ими.

Фашистка каршы көрәшне
Шигырендә дәвам итә.

Җиңүнең безгә килерен
Белеп, ышанып үлә.

Алиш абый үлемне дә
Батырларча каршылый.
Туган иле, халкы өчен
Гомерен ул жәлләми.

Хәзер ул халык телендә
«Каһарман» исмен йөртә.
Өзелгән иҗаты аның
Бездә дә дәвам итә!

*Динара Фәсхетдинова,*
*7 «В» сыйныфы укучысы.*

15

## Котлыйм сине

Әниемне сагынып
Кайтып киләм мәктәптән.
Әнием бәйрәменә мин
«Биш»ле алдым бар фәннән.
Әнием моңа шатланып:
«Кызым, афәрин!» – диде.
Аның сөенгәнен күреп,
Яхшылык эшлисем килде.
Әниемне яратам шул,
Әни – минем терәгем.
Бәйрәм көнендә әнигә
Озын гомер теләдем.
Бәхетле бул, син, әнием,
Йөзең гел көләч булсын.
Бәйрәмеңдә сине котлап,
Көнем елмаеп торсын.

**Руфилә ШАКИРОВА,**
*Чаллы, 45нче урта мәктәп,*
*9нчы сыйныф.*

## Җәлилчеләр

Казан. Кремль янында
Тора Җәлил һәйкәле.
Бу һәйкәлне белмәгән
Кеше бармы, әйт әле?!

Казан – татар мәркәзе,
Анда кемнәр килмәгән.
Кемнәр генә бу һәйкәлгә
Чал башларын имәгән.

Тора Җәлил горур гына
...әгърур башын күтәргән.
Аягын ураган чылбыр
...ит коллыкка илтмәгән.

...рәштәш дуслары аның
...ннарына тезелгән.

Дошман бәйләгән чылбырлар,
Буйсынмагач, өзелгән.

Сугыш кырларыннан алар
Исән кайта алмады.
Күпме тырышса да дошман,
Баш идерә алмады

«Барельеф»ка килеп бастым,
Торам карап тын гына.
Җәлилчеләр тавышын ишетәм:
«Без үлмәдек, без монда…»

Татар халкы бүген тагын
Шушы һәйкәлгә килде:
«Булмасын сугышлар бүтән,
Тыныч йоклагыз», – диде.

*Кафия Гыйззәтуллина,*
*45нче мәктәпнең татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы.*

11

Чаллы шәһәре, ...
мәктәбе, 8Б сыйныфы у...
лары яза. Укытуч...
Кафия Гыйззәту...

## Салкын тышта

Килеп җитте кыш та,
Ай-яй салкын тышта.
Яңа чанасын күтәреп
Азат чыкты тышка.
Урамдагы чиста кар
Җемелдәп төрле төстә.
Урамда салкын икән,
Җылы булса да өстә.
Безнең өй янында,
Биек, шома тау бар.
Шул таудан очып
Чана шуа балалар.
Азат та бик куанды,
Чана шуа башлады.
Кыш бабайга рәхмәт,
Кайтасы килми башлады.

**Динара ВӘЛИӘХМӘТОВА.**

## Кардан челтәрләр үрде

Кыш бабай да килеп җитте
Кар-бураннары белән.
Бар җиһанны күмде акка
Дөнья чистарсын, дигән.
Агачларны япты карга,
Алар туңмасын, дигән.
Язга кадәр бар җиһан
Тыныч йокласын, дигән.
Көчле җил дә исеп куйды,
Кар көртләрен күп өйде.
Сызгырып буран туздырды,
Әкияттәге җен төсле.
Кар кызы шушы җиһанга
Елтыр бөртекләр тезде.
Күрегез матурлыкны дип,
Кардан челтәрләр үрде.

**Николай КОЛЧЕРИН.**

## Тәрәз... би...

Өй янына к...
Тәрәзәләрн...
Тәрәзәдәге...
Кыш баба...
Бу бизәк...
Әкиятт...
Әйтерс...
Сихри...
Бәсле...
Кечк...
Шу...
Кы...
Бу...
Й...
М...

## Герой шагыйрь

Безнең өчен, Муса абый,
Бик күп шигырьләр яздың.
Мәңгелек иҗатың белән
Бөтен илгә танылдың!

Син фашистлар тоткынында
Күп батырлыклар кылдың.
Үлмәс әсәрләрең белән
Гомергә истә калдың.

Бу дөньядан китеп бардың
Өмет белән җиңүгә.

«Батыр Җәлил»нең иҗаты
Калды халык күңелендә.

Киләчәк якты булсын, дип,
Керде Муса утларга…
Күр, халкың бүген, җыелып,
Килде сине котларга!

Ватан өчен бирде гомерен,
Ватан улы ул – Муса.
Аның шигырен укыйбыз
Дәреслектән, көн туса.

*Альберт Минеев,*
*Яр Чаллының 45нче мәктәп укучысы.*

14

«Мокамай» әсәрен, Габдулла абый Тукайның «Су анасы»н, «Шүрәле»сен, «Кәҗә белән Сарык» әкиятен яттан белә ул. Муса абый Җәлилнең нинди генә шигырьләрен сөйләми! Кафия апабыз үзе дә шигырьләр яза. Безгә дә шигырьләр язарга куша. Роберт абый Миңнуллин юлларын еш кабатлый:

*Күңелләргә шигырь кирәк,*
*Шигырь ул – тылсым.*
*Шигырь сезнең җаныгызны*
*Җылытып торсын.*

Һәр ел фасылы турында, язучылар турында шигырьләр яздык. Әле язып кына калмыйбыз, апабыз аларны «Көмеш кыңгырау» газетасына, «Мәйдан» журналына җибәреп бастырып та чыгара. Шигырьләребез басылган газеталар саны инде 53 булды. Без аларны горурланып җыеп барабыз.

Кафия апаның ел саен уздырып, традициягә әйләнгән шөгыле дә бар. Мәктәпнең Актлар залында Чаллы язучылары белән очрашулар уздыра ул. Язучы абый-апалар белән төшкән фотосурәтләр мәктәп музеенда саклана. «Җиде кат ишеткәнче, бер кат күрүегез яхшырак», – ди язучылар турында апабыз.

Безнең мәктәптән ерак түгел генә 12нче татар китапханәсе урнашкан. Апа безне еш кына китапханәдә узган чараларга, язучылар белән очрашуларга алып бара. Без анда барып, Факил абый Сафин, Рәшит абый Бәшәр, Зифа апа Кадыйрова, Фәүзия апа Бәйрәмова белән очраштык.

Яңа чыккан китаплар, басмалар белән дә гел танышып барабыз. Быел менә «Ялкын» журналы белән таныша башладык. Шигырьләребезне сезгә дә җибәреп карарга булдык. Насыйп булса, дуслашып та китәрбез, бәлки!

*Гүзәл Халилова,*
*Яр Чаллы шәһәрендәге*
*45нче мәктәпнең*
*9 «Б» сыйныфы укучысы.*

3

# Массакүләм чаралар белән тыгыз бәйләнештә эшлибез.



тучылар да, мәктәбебезнең ата-аналары да бу эштә бик теләп катнашалар.

Әлбәттә, тырышып эшләгән эшнең нәтиҗәсе булмый калмый. Менә инде 5 ел рәттән безнең «Аргамак» командасы җиңүчеләр рәтендә. Татар телен үстерүгә керткән лаеклы өлеше өчен мәктәбебез Чаллы шәһәренең башкарма комитеты тарафыннан «Рәхмәт хаты», Татарстан Мәгариф һәм Фән министрлыгы Дипломы белән бүләкләнде

Бу уку елы да безнең өчен уңышлы булырга ошаган. «Әкиятләр күңел байлыгы», «Халкымның бер баласы мин» бәйгеләрендә 1 урыннарны яуласак, «Теле барның – иле бар» фестивалендә катнашып 2нче дәрәҗә дипломга лаек булдык.

Алда безне тагын өч сынау көтә. Без анда да сынатмабыз дип уйлыйбыз.

**Мөкәррәмә КОВАЛЬ,**
*Чаллы, 45нче мәктәпнең «Аргамак» командасы җитәкчесе*

## Сынатырга уйламыйбыз

Күп еллар дәвамында «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә катнашу безгә уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Елдан-ел тәҗрибә туплап остарабыз. Безнең «Аргамак» командасы гел җиңүчеләр рәтендә. Быел да сынатырга уйламыйбыз.

Акциянең II турында «Мин сугышның ни икәнен беләм» иҗади эшләр бәйгесендә катнашып 1нче һәм II дәрәҗәле дипломнарга лаек булдык. III турында «Муса безнең йөрәкләрдә» шигырь бәйгесендә 3нче урынга лаек булдык. Йомгаклау турына шәһәребезнең җәмәгать урыннарына барып, шәһәр- дәшләребез белән татар телененең бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер алыштык. Кешеләрнең татар теленә карата булган җылы мөнәсәбәтләре безне бик шатландырды, алдагы үрләрне яуларга көч өстәде.

*6Г сыйныфы укучыларыннан төзелгән «Аргамак» командасы, 45нче мәктәп, Чаллы.*



## И, туган тел!

**Халыкара Туган тел көнен билгеләп үтү шәһәр мәктәпләрендә, шул исәптән, безнең 45нче мәктәптә дә матур бер традициягә әйләнде. Туган тел — һәркем өчен газиз. Ул телдә әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез сөйләшкән. Туган тел көне быел да күңелләрне дулкынландырырлык, хәтердә калырлык булды.**

Мәктәпкә керүгә һәркемне укучылар тарафыннан туган телгә багышлап чыгарылган газета белән каршы алдылар. Сыйныф бүлмәләрендә "Туган тел — изге тел", "Туган телең — изге анаң", "Туган телсез кеше — канатсыз кош" кебек мәкальләр язып элделәр. Ә Тукайның "Туган тел" шигыре бу көннәрдә аеруча сихри, матур яңгырады.

Әйе, мәктәбебездә туган телгә мәхәббәт, аның белән чиксез горурлану хисләрен уятуда бик күп чаралар оештырыла. Туган телгә багышланган шигырь бәйгесендә дә төрле милләт балалары бик тырышып, берсеннән-берсе сәнгатьлерәк итеп, үзләренең яраткан шигырьләрен укыдылар. Ә әкиятләр кичәсе беркемне дә битараф калдырмады — мавыктыргыч һәм кызыклы булды.

Югары сыйныф укучылары үзләренең туган телгә булган ихтирам хисләрен фәнни күзлектән чыгып аңлаттылар. Алар дәресләрдә "Туган телем — изге тел" темасына фәнни эшләр бәйгесе оештырдылар, кеше тормышында туган телнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын дәлилләделәр.

Атналыкны йомгаклау мәҗлесләр залында Туган тел кичәсе белән тәмамланды. Төрле милләт балаларының үз ана телләрендә укыган шигырьләре, җырлаган җырлары, биюләре кунакларның да, укучыларның да сөендерде. Кичәдән һәркем күтәренке кәеф белән таралышты.

Туган телне күз карасы кебек сакларга кирәк, чөнки телен югалткан милләтнең киләчәге юк. Үз телен хөрмәт иткән кеше генә милләте белән горурлана, аның кадерен белә.

**М.КОВАЛЬ,**
**татар теле укытучысы**

## СЫНАТМАБЫЗ

**Республика күләмендә уздырыла торган "Мин татарча сөйләшәм" акциясенә әзерлек безнең 45нче мәктәптә берничә ел инде уку елы башыннан даими алып барыла.**

Укучылар да, укытучылар да, мәктәбебезнең ата-аналары да бу эштә бик теләп катнашалар. Ник дигәндә, алты этаптан торган шәһәр туры ча-



ы укучыларның күздә тотып рә анда катнашу ып, күңел биреп ң нәтиҗәсе булмый калмый. Менә инде 5 ел рәттән безнең "Аргамак" командасы җиңүчеләр рәтендә. Татар телен үстерүгә керткән лаеклы өлеше өчен мәктәбебез Яр Чаллы шәһәре башкарма комитетының Рәхмәт хаты, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломы белән бүләкләнде.

Бу уку елы да безнең өчен бик уңышлы булырга охшаган. "Әкиятләр — күңел байлыгы", "Халкымның бер баласы мин" бәйгеләрендә беренче урыннарны яуласак, "Теле барның иле бар" фестивалендә катнашып, 2нче дәрәҗәле дипломга лаек булдык. Телләгебез — "Мин татарча сөйләшәм" республикакүләм акциясендә катнашып, татар телен, халкыбызның матур йолаларын, гореф-гадәтләрен саклап калу юнәлешендә эшчәнлегебезне күрсәтү.

Алда безне тагын өч сынау көтә. Аларда да "Аргамагыбыз" уңышларга ирешсен өчен тырышырбыз.

**Р.КОВАЛЬ,**
**45нче мәктәпнең "Аргамак" командасы җитәкчесе**